**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2021 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Күк-Тәкә торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**26 октябрь 2020 ел** **№2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлеге Күк-Тәкә торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2021 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 200 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Күк-Тәкә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

- Күк-Тәкә авылында янгын сүндерү техникасын карап тоту (машина йөртүченең хезмәте өчен килешү буенча түләү);
- Күк-Тәкә авылы зиратын койма белән әйләндереп алу өчен материал сатып алу;
- Күк-Тәкә авылында «Халыкара хатын-кызлар көне» «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», инвалидлар декадасы, «Яңа ел» бәйрәм чараларын үткәрү өчен бүләк, сувенир продукциясе сатып алу;
- Күк-Тәкә авылының М.Җәлил урамы, Яшьләр урамы зиратларында контейнер мәйданчыклары һәм аларга киртәләр урнаштыру өчен материаллар сатып алу, коймалар ясау һәм урнаштыру, контейнер мәйданчыкларын һәм аларның нигезен урнаштыру.

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Тымытык авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Тымытык авыл җирлеге башлыгы Э.Х. Гыйләҗева